**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның 17 нче июненнән — № 45-164

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19, 86-88 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

2015 елның 10 мартындагы 37-116 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (19.10.2015 №2-9; 04.03.2016 №8-27; 28.11.2016 №15-50; 19.04.2017 №18-64; 31.08.2017 №21-74; 19.12.2017 №26-83; 26.06.2018 №31-104; 19.12.2018 №38-131; 15.07.2019 №46-154; 15.06.2020 №56-184; 31.05.2021 №10-34; 28.12.2021 №17-64; 14.10.2022 №23-86; 26.04.2023 №27-101; 28.03.2024 №34-130; 28.12.2024 № 40-150 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Уставның 1 статьясындагы 2 пунктында «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «, кыскартылган исеме « Яңа Чишмә АҖ» сүзләрен өстәргә.

1.2. Уставның 29 статьясының 7.6 өлеше үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. Уставның 32 статьясының 26 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. Уставның 84 статьясындагы 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджеты проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм җирлек Советы карары нигезендә җирлек башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм вакытларда төзелә.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы урынбасары О.И. Лазарева